ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

22 август, 2022 ел | № 16/11

Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, ««Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/15, 2016 елның 18 маендагы 8/6, 2016 елның 8 июлендәге 9/11, 2020 елның 28 маендагы 39/7, 2020 елның 29 декабрендәге 4/6 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктның 29 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев